

# Туган телең бер генә,
# Аның кадерен бел генә !

# Максатыбыз

1.Милли телебез буларак татар телен торгызу, саклау,үстерү юлларын тикшерү.

2.Һәр илнең ачкычы буларак – тел икәнен ачыклау.

3.Телнең югалмас ядкарь икәнен күрсәтү.

4.Татар теленең үсешенә караган мәсьәләләрне барлау.

5. Мәгариф системасында телләрне өйрәнүнең торышы.

# Бурычлар:

1.Үз телеңне саклау – безнең изге бурычыбыз.

2. Кеше тормышында аерылгысыз төшенчәнең берсе - аның туган теле дип санау.

3.Иҗади фикерле белү сәләтен үстерү.

**Туган телебезне Габдулла Тукайдан башка күз алдына китереп булмый. Күп кенә эшчәнлегебез аның иҗатына барып тоташа.**

1. Дөньякүләм татар теле һәм әдәбияттыннан тестка әзерлек максатында Тукай иҗатын пропагандалау йөзеннән, укучылар белән Габдулла Тукайның иҗатын һәм тормыш юлын яктырткан презентацияләр, төрле фильмнар карау оештырылды. Аннан соң бирелгән викторина сораулары укучыларны тагын да җанландырып җибәрде. Г. Тукайның 130 еллыгына багышланган "И туган тел, и матур тел" дөньякүләм тест эшендә Хәбетдинов Нәфис, Мансурова Лияләр катнашып, сертификат белән бүләкләнделәр.

2."Габдулла Тукай образының әдәбият, музыка һәм сәнгатьтә чагылышы» I районкүләм иншалар бәйгесенең мәктәп этабында 6-8 класс укучылары катнашты. Әлеге конкурс укучыларның фәнни-иҗади эш белән шөгыльләнүгә этәргеч булды. Җиңүче 8нче класс укучысы Хәбетдинов Нәфиснең эше район этабына җибәрелде. Сертификатка ия булды.

3. КФУ уздырган "Аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды...” россиякүләм шигырь укучылар конкурсына 5 укучының (Ильдарханов Динар -“Эш беткәч, уйнарга ярый, Мансурова Лия -“Теләнче”, Шарапова Айгизә-“Бәйрәм вә сабыйлык вакыты”, Хәбетдинова Язилә- Бер татар шагыйренең сүзләре”, Хәбетдинов Нәфис-“Кечкенә музыкант”) шигырьләре видеога төшерелеп җибәрелде. Укучылар сертификат белән бүләкләнделәр.


ТУКАЙ БЕЗНЕҢ КУНЕЛЛәр



**Арчада уздырылган Габдулла Тукайның иҗади мирасын өйрәнүгә багышланган V Республикакүләм « Без – Тукайлы халык» фәнни-гамәли конференциясендә «Габдулла Тукай –күпкырлы шәхес» ( Хәбетдинов Нәфис); «Казаныбызда Тукайга бәйле истәлекле урыннар» (Мирзаянов Илнар) темаларына бик матур чыгыш ясап кайттылар. Диплом һәм истәлекле бүләкләргә ия булдылар.**



**Актанышта узган «Туган телем- шагыйрьләр теле” III республика фәнни- эзләнү конференциясендә Хәбетдинов Нәфис һәм Мансурова Лиянең “Мөхәммәт Мирза иҗатының тәрбияви әһәмияте” темасына җибәрелгән эшләре диплом белән бүләкләнде.**

**Арчада уздырылган Габдулла Тукайның иҗади мирасын өйрәнүгә багышланган V Республикакүләм «Без – Тукайлы халык» укуларының «Тукай рухы- һәрчак күңелләрдә» номинациясендә укучылар командасы диплом белән бүләкләнде. Җитәкчеләре: Мирзаянова Рания Сәгыйть кызы һәм Ли Ләйлә Рифкать кызы.**

“Йолдызлык”республика фестивале район этабының “Конферанс” номинациясендә татар әдәбиятын яратучы нәфис сүз осталары Мансурова Лия һәм Илдарханов Динар һәр ел саен уңышлы чыгыш ясап диплом белән бүләкләнәләр.

**“Илһам” Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенә Мансурова Лия, Хәбетдинова Язилә, Шарапова Айгизә, Хәбетдинов Нәфисләрнең иҗади эшләрен җибәрдек. Уңышлар көтеп калабыз!**

Дипломнар



**Татар теле – туган тел,**
**Безнең газиз булган тел.**
**Әти-әни, әби-бабай**
**Безне сөя торган тел.**

**Шәйхи Маннур**

К.Г.Паустовский тел турында болай дигән:

“Туган теленә битараф кеше кыргый. Ул үзенең табигате белән үк зыянлы. Чөнки аның телгә карата битарафлыгы үз халкының үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә битараф булуы белән аңлатыла”.



И туган тел, и матур тел,
Әткәм, әнкәмнең теле;
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син, туган тел,
аркылы.

Г. Тукай

Организация
Объединенных Наций по
вопросам образования
науки и культуры

*1999 нчы елның ноябрендә, Бангладеш дәүләте тәкъдиме белән, ЮНЕСКО Генераль конференциясе, ЮНЕСКОга кергән илләр һәм Берләшкән Милләтләр оешмасы 21 февраль көнен Туган тел көне дип игълан итте.*

*Беренче мәртәбә ул 2000 нче елның 21 февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.*

# *21 февраль – Халыкара туган тел көне*

Үз телемдә шигырь укыйм,
Үз телемдә сөйли алам.
Туган җирем, туган илем,
Мин бит синнән илһам алам.
Хәтта кошның да туган теле бар,
Теле булганның гына иле бар.
Бабаларымның иң зур мирасы,
Чиксез галәмнең гүя моңы син.
Яшә мәңгегә
И туган телем,
Былбыл моңыдай,
И матур телем.

**Дөньяда 6000 нән артык телдә сөйләшәләр.**
**Аларның һәрберсе авазлар,**
**мәгънәләр һәм грамматик кагыйдәләрнең**
**катлаулы системасыннан тора.**

**Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә**
**тигез дәрәҗәдә итеп**
**танылa, чөнки һәр тел кеше халәтенә бердәнбер**
**җавап һәм без сакларга**
**тиеш тере мирас булып тора.**
**Коитиро Мацуура – ЮНЕСКО**
**Генераль директоры**

UNESCO

Организация Объединенных Наций по вопросам образования науки и культуры

Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе:

***ИНГЛИЗ, НЕМЕЦ, ФРАНЦУЗ, ИСПАН, ИТАЛЬЯН, ПОРТУГАЛ, ГАРӘП, ФАРСЫ, РУС, КЫТАЙ, ТӨРЕК, ЯПОН, ҺИНД, ТАТАР ТЕЛЛӘРЕ.***

Татар телен белгән кеше 30 дан артык төрки халык белән җиңел аңлаша һәм аралаша ала

***Татарча да яхшы бел,***

***Русча да яхшы бел,***

***Икесе дә безнең өчен***

***Бик кирәкле, затлы тел.***

***Шәйхи Маннур***





*Тел –*
*халык күңеленең*
*кыңгыравы.*
*Ә кыңгырау -*
*кагылмасаң*
*чыңламый.*
*Ф.*
*Яруллин*

Телне йөзек кашы белән генә чагыштыру да аздыр. Ул — милләтнең җаны. Тел үлсә, милләт тә яшәми. Ул авыру булса, милләт тә чирли. Аны сакларга, кадерләргә кирәк.

Чәбәләнгән телем кат-кат,
Йолкып-тартып тетмәгез.
Үрмәләр өчен үрләргә,
Телне аркан итмәгез!

Кил, өйрән, и туган,
бер башка телне,
Бүтән телләр белү –
яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вә ләкин
телгә телне,
Тел уйнатмак
наданлыктан әсәрдер.

Дәр
демәнд



Туган җирем – Идел буе,
Һәркемнең бар туган иле.
Туган җирем кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй мөкатдәс татар теле,
Әй син батыр татар теле!

Нажар Нәҗми



***И минем җандай кадерлем***
***И җылы, тере телем!***

***Х.Туфан***




Ишеттем мин кичә:
берәү җырлый
Чын безнеңчә
матур, милли көй;
Башка килә
уйлар төрле-төрле,
—
Әллә нинди зарлы,
моңлы көй

Тел дигән дәрья бар,
Дәрья төбендә мәрҗән бар.
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгән карап калыр.

Нәкый Исәнбәт

Тел ачылгач , үз телеңдә әйтә алсаң
“Әни” дип,
Тел ачылгач , үз телеңдә әйтә алсаң
“Әти” дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң
“Әни” дип,
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң
“Әти” дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр
Туган телең әнә шул булыр.

*Зөлфәт*



Татар телем,
Үсеп,сиңа алга барасы –
Гасырларын кичеп, чорларга.
Теләгем шул:
Яңа дәвер, яңа чорларда
Насыйп булсын сөйгән халкыма,
Сәйдәш маршын уйнап
Сөекле “Туган тел”не җырларга.